# ЗАКОН
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О наделении органов местного самоуправления муниципальных районов Республики Татарстан государственными полномочиями Республики Татарстан по распоряжению земельными участками, государственная собственность на которые не разграничена**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
23 декабря 2015 года

Настоящий Закон в соответствии с Федеральным законом от 6 октября 2003 года № 131-ФЗ «Об общих принципах организации местного самоуправления в Российской Федерации», Законом Республики Татарстан от 28 июля 2004 года № 45-ЗРТ «О местном самоуправлении в Республике Татарстан», иными нормативными правовыми актами Российской Федерации и Республики Татарстан наделяет органы местного самоуправления муниципальных районов Республики Татарстан (далее – органы местного самоуправления) государственными полномочиями Республики Татарстан по распоряжению земельными участками, государственная собственность на которые не разграничена.

Статья 1. **Государственные полномочия Республики Татарстан, которыми наделяются органы местного самоуправления**

Органы местного самоуправления наделяются государственными полномочиями Республики Татарстан по распоряжению земельными участками, государственная собственность на которые не разграничена, расположенными на территориях городских, сельских поселений, входящих в состав муниципального района, в которых утверждены правила землепользования и застройки поселения, за исключением полномочий по предоставлению земельных участков для размещения автомобильных дорог регионального или межмуниципального значения (далее – государственные полномочия).

Статья 2. **Наименования муниципальных образований Республики Татарстан, органы местного самоуправления которых наделяются государственными полномочиями**

Государственными полномочиями наделяются органы местного самоуправления следующих муниципальных образований Республики Татарстан:

Агрызский муниципальный район, Азнакаевский муниципальный район, Аксубаевский муниципальный район, Актанышский муниципальный район, Алексеевский муниципальный район, Алькеевский муниципальный район, Альметьевский муниципальный район, Апастовский муниципальный район, Арский муниципальный район, Атнинский муниципальный район, Бавлинский муниципальный район, Балтасинский муниципальный район, Бугульминский муниципальный район, Буинский муниципальный район, Верхнеуслонский муниципальный район, Высокогорский муниципальный район, Дрожжановский муниципальный район, Елабужский муниципальный район, Заинский муниципальный район, Зеленодольский муниципальный район, Кайбицкий муниципальный район, Камско-Устьинский муниципальный район, Кукморский муниципальный район, Лаишевский муниципальный район, Лениногорский муниципальный район, Мамадышский муниципальный район, Менделеевский муниципальный район, Мензелинский муниципальный район, Муслюмовский муниципальный район, Нижнекамский муниципальный район, Новошешминский муниципальный район, Нурлатский муниципальный район, Пестречинский муниципальный район, Рыбно-Слободский муниципальный район, Сабинский муниципальный район, Сармановский муниципальный район, Спасский муниципальный район, Тетюшский муниципальный район, Тукаевский муниципальный район, Тюлячинский муниципальный район, Черемшанский муниципальный район, Чистопольский муниципальный район, Ютазинский муниципальный район.

Статья 3. **Срок, на который органы местного самоуправления наделяются государственными полномочиями**

Органы местного самоуправления наделяются государственными полномочиями сроком на пять лет.

Статья 4. **Финансовое обеспечение переданных органам местного самоуправления государственных полномочий**

1. Финансовое обеспечение переданных органам местного самоуправления государственных полномочий осуществляется за счет предоставляемых бюджетам муниципальных районов субвенций из бюджета Республики Татарстан.

2. Расчет объема субвенций, предоставляемых бюджетам муниципальных районов из бюджета Республики Татарстан для осуществления органами местного самоуправления государственных полномочий, производится в соответствии с Методикой расчета объема субвенций, предоставляемых бюджетам муниципальных

районов из бюджета Республики Татарстан для осуществления органами местного самоуправления государственных полномочий Республики Татарстан по распоряжению земельными участками, государственная собственность на которые не разграничена, согласно приложению к настоящему Закону.

3. Объем субвенций, предоставляемых бюджетам муниципальных районов из бюджета Республики Татарстан для осуществления органами местного самоуправления государственных полномочий, устанавливается законом Республики Татарстан о бюджете Республики Татарстан на очередной финансовый год.

Статья 5. **Материальные средства, передаваемые в безвозмездное пользование органам местного самоуправления для осуществления государственных полномочий**

1. Материальные средства, находящиеся в собственности Республики Татарстан, в случае необходимости обеспечения осуществления органами местного самоуправления государственных полномочий передаются в безвозмездное пользование органам местного самоуправления в соответствии с Перечнем передаваемых материальных средств.

2. Разработка Перечня передаваемых материальных средств, его утверждение и принятие решения о передаче материальных средств осуществляются органом исполнительной власти Республики Татарстан, уполномоченным в области земельных отношений, с учетом предложений органов местного самоуправления.

Статья 6. **Права и обязанности органов местного самоуправления при осуществлении государственных полномочий**

1. Органы местного самоуправления при осуществлении государственных полномочий имеют право:

1) дополнительно использовать собственные материальные и финансовые средства для осуществления государственных полномочий в случаях и порядке, предусмотренных уставом муниципального образования;

2) вносить предложения по совершенствованию деятельности, связанной с осуществлением государственных полномочий;

3) получать в органах государственной власти Республики Татарстан информационную, консультативную, организационную и методическую помощь по вопросам осуществления государственных полномочий.

2. Органы местного самоуправления при осуществлении государственных полномочий обязаны:

1) осуществлять государственные полномочия в соответствии с законодательством Российской Федерации и законодательством Республики Татарстан;

2) представлять уполномоченным органам исполнительной власти Республики Татарстан документы и необходимую информацию по вопросам, связанным с осуществлением государственных полномочий;

3) ежеквартально представлять отчеты об осуществлении государственных полномочий в орган исполнительной власти Республики Татарстан, уполномоченный в области земельных отношений;

4) оказывать необходимое содействие уполномоченным органам исполнительной власти Республики Татарстан в осуществлении контроля за исполнением органами местного самоуправления государственных полномочий.

Статья 7. **Права и обязанности органов государственной власти Республики Татарстан при осуществлении органами местного самоуправления государственных полномочий**

1. Органы государственной власти Республики Татарстан при осуществлении органами местного самоуправления государственных полномочий имеют право:

1) запрашивать документы и информацию у органов местного самоуправления и (или) должностных лиц органов местного самоуправления по вопросам, связанным с осуществлением государственных полномочий;

2) проводить проверки деятельности органов местного самоуправления по осуществлению государственных полномочий;

3) давать письменные предписания по устранению выявленных нарушений законодательства по вопросам осуществления органами местного самоуправления и (или) должностными лицами органов местного самоуправления государственных полномочий.

2. Органы государственной власти Республики Татарстан при осуществлении органами местного самоуправления государственных полномочий обязаны:

1) передавать органам местного самоуправления материальные и финансовые средства, необходимые для осуществления государственных полномочий;

2) осуществлять контроль за исполнением органами местного самоуправления государственных полномочий, а также за использованием предоставленных на эти цели материальных и финансовых средств;

3) оказывать информационную, консультативную, организационную и методическую помощь по вопросам осуществления органами местного самоуправления государственных полномочий.

Статья 8. **Порядок отчетности органов местного самоуправления об осуществлении государственных полномочий**

Отчеты об осуществлении государственных полномочий представляются органами местного самоуправления в орган исполнительной власти Республики Татарстан, уполномоченный в области земельных отношений, в срок до 10 числа месяца, следующего за отчетным кварталом, по форме, установленной Кабинетом Министров Республики Татарстан.

Статья 9. **Контроль за осуществлением органами местного самоуправления государственных полномочий**

Контроль за осуществлением органами местного самоуправления государственных полномочий осуществляется:

1) органом исполнительной власти Республики Татарстан, уполномоченным в области земельных отношений, в части надлежащего осуществления государственных полномочий путем:

а) запросов необходимых документов, отчетов и информации об осуществлении государственных полномочий;

б) проведения выездных проверок деятельности органов местного самоуправления по осуществлению государственных полномочий согласно плану, ежегодно утверждаемому указанным органом, а также по мере необходимости внеплановых выездных проверок;

2) органом исполнительной власти Республики Татарстан, уполномоченным в области финансовой политики, в части целевого использования финансовых средств, переданных для осуществления государственных полномочий, путем:

а) запросов необходимых документов, отчетов и информации об осуществлении государственных полномочий;

б) проведения по мере необходимости выездных проверок деятельности органов местного самоуправления по осуществлению государственных полномочий, в том числе по результатам рассмотрения запрошенных ранее документов, отчетов и информации, а также в связи с выявленными фактами нарушения законодательства;

в) принятия необходимых мер по устранению нарушений законодательства и их предупреждению;

3) в случае передачи в безвозмездное пользование органам местного самоуправления материальных средств, находящихся в собственности Республики Татарстан, для осуществления государственных полномочий органом исполнительной власти Республики Татарстан, уполномоченным в области земельных отношений, в части сохранности и надлежащего использования государственного имущества, переданного органам местного самоуправления для осуществления государственных полномочий, путем:

а) запросов необходимых документов, отчетов и информации об осуществлении государственных полномочий;

б) проведения по мере необходимости проверок деятельности органов местного самоуправления по осуществлению государственных полномочий, в том числе по результатам рассмотрения запрошенных ранее документов, отчетов и информации, а также в связи с выявленными фактами нарушения законодательства;

в) принятия необходимых мер по устранению нарушений законодательства и их предупреждению.

Статья 10. **Условия и порядок прекращения осуществления органами местного самоуправления государственных полномочий**

1. Прекращение осуществления органами местного самоуправления

государственных полномочий производится законом Республики Татарстан в случае:

1) неисполнения или ненадлежащего исполнения органами местного самоуправления требований законодательства в области регулирования государственных полномочий;

2) неисполнения органами местного самоуправления и (или) должностными лицами органов местного самоуправления предписаний об устранении нарушений настоящего Закона;

3) изменения законодательства Российской Федерации или законодательства Республики Татарстан, в результате которого осуществление органами местного самоуправления государственных полномочий становится невозможным.

2. Прекращение осуществления органами местного самоуправления государственных полномочий влечет за собой возврат неиспользованных материальных и финансовых средств, находящихся в собственности Республики Татарстан, переданных для осуществления государственных полномочий.

3. В случае неисполнения или ненадлежащего исполнения органами местного самоуправления требований законодательства по осуществлению государственных полномочий орган исполнительной власти Республики Татарстан, уполномоченный в области земельных отношений, в течение 10 дней со дня выявления указанных нарушений направляет в орган местного самоуправления предписание об их устранении.

4. Предписание об устранении выявленных нарушений подлежит обязательному рассмотрению не позднее чем в десятидневный срок со дня его поступления в органы местного самоуправления. О результатах рассмотрения предписания незамедлительно сообщается в письменной форме в орган исполнительной власти Республики Татарстан, уполномоченный в области земельных отношений.

5. В случаях, предусмотренных частью 1 настоящей статьи, орган исполнительной власти Республики Татарстан, уполномоченный в области земельных отношений, вносит на рассмотрение Кабинета Министров Республики Татарстан предложение о прекращении осуществления органами местного самоуправления государственных полномочий и соответствующий проект закона Республики Татарстан.

Статья 11. **Заключительные положения**

1. Настоящий Закон вступает в силу с 1 января 2016 года.

2. Нормативные правовые акты органов государственной власти Республики Татарстан и органов местного самоуправления подлежат приведению в соответствие с настоящим Законом в течение трех месяцев со дня вступления его в силу.

Президент
Республики Татарстан Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
26 декабря 2015 года
№ 109-ЗРТ

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Приложение
к Закону Республики Татарстан
«О наделении органов местного
самоуправления муниципальных районов
Республики Татарстан государственными
полномочиями Республики Татарстан по
распоряжению земельными участками,
государственная собственность на
которые не разграничена»

МЕТОДИКА
расчета объема субвенций, предоставляемых
бюджетам муниципальных районов из бюджета Республики Татарстан для
осуществления органами местного самоуправления государственных полномочий
Республики Татарстан по распоряжению земельными участками, государственная
собственность на которые не разграничена

1. Настоящая Методика предназначена для расчета объема субвенций, предоставляемых бюджетам муниципальных районов из бюджета Республики Татарстан для осуществления органами местного самоуправления государственных полномочий.

2. Объем субвенций, предоставляемых j-му муниципальному району из бюджета Республики Татарстан на осуществление органами местного самоуправления государственных полномочий, рассчитывается по формуле:

$$C_j^z = N^z \times H_j,$$

где:

$C_j^z$ – объем субвенций, предоставляемых j-му муниципальному району из бюджета Республики Татарстан на осуществление органами местного самоуправления государственных полномочий;

$N^z$ – норматив для определения объема субвенций j-му муниципальному району на осуществление органами местного самоуправления государственных полномочий на один гектар земельного участка, государственная собственность на который не разграничена (рублей на гектар);

$H_j$ - площадь земельных участков, государственная собственность на которые не разграничена в j-м муниципальном районе (гектаров).

3. Норматив для определения объема субвенций j-му муниципальному району на осуществление органами местного самоуправления государственных полномочий на один гектар земельного участка, государственная собственность на который не разграничена, рассчитывается по формуле:

$$N^z = \frac{R}{\sum_{j=1}^{n} H_j},$$

где:

R – прогнозные расходы на осуществление органами местного самоуправления государственных полномочий;

n – количество муниципальных районов.

4. Прогнозные расходы на осуществление органами местного самоуправления государственных полномочий рассчитываются по формуле:

$$R = (\sum_{j=1}^{n} S_j \times t_{усл.}) \times Z_1,$$

где:

$S_j$ – количество услуг по предоставлению земельных участков, государственная собственность на которые не разграничена, предоставляемых в j-м муниципальном районе в год;

$t_{усл.}$ – время, необходимое для предоставления услуги по предоставлению земельных участков, государственная собственность на которые не разграничена, главным специалистом исполнительного комитета j-го муниципального района (устанавливается в размере двух рабочих дней);

$Z_1$ – заработная плата с начислениями на фонд оплаты труда главного специалиста исполнительного комитета j-го муниципального района за один рабочий день.

5. Количество услуг по предоставлению земельных участков, государственная собственность на которые не разграничена, предоставляемых в j-м муниципальном районе в год, рассчитывается по формуле:

$$S_j = К_{ср} \times Н_j,$$

где:

$К_{ср}$ – коэффициент, определяющий среднее количество запросов на предоставление услуги по предоставлению земельных участков, государственная собственность на которые не разграничена, на один гектар, равный 0,005.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 23 декабрендә
кабул ителде

Әлеге Закон "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына (алга таба – җирле үзидарә органнары) дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирә.

**1 статья. Җирле үзидарә органнарына бирелә торган Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләре**

Җирле үзидарә органнарына муниципаль район составындагы җирдән файдалану һәм җирлек төзү кагыйдәләре расланган шәһәр, авыл җирлекләре территорияләрендә урнашкан дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү буенча, җир кишәрлекләрен региональ яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юллары урнаштыру өчен бирү вәкаләтләреннән тыш, Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләре (алга таба – дәүләт вәкаләтләре) бирелә.

**2 статья. Җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләре бирелә торган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре исемнәре**

Дәүләт вәкаләтләре Татарстан Республикасының түбәндәге муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына бирелә:

Әгерҗе муниципаль районы, Азнакай муниципаль районы, Аксубай муниципаль районы, Актаныш муниципаль районы, Алексеевск муниципаль

районы, Әлки муниципаль районы, Әлмәт муниципаль районы, Апас муниципаль районы, Арча муниципаль районы, Әтнә муниципаль районы, Баулы муниципаль районы, Балтач муниципаль районы, Бөгелмә муниципаль районы, Буа муниципаль районы, Югары Ослан муниципаль районы, Биектау муниципаль районы, Чүпрәле муниципаль районы, Алабуга муниципаль районы, Зәй муниципаль районы, Зеленодольск муниципаль районы, Кайбыч муниципаль районы, Кама Тамагы муниципаль районы, Кукмара муниципаль районы, Лаеш муниципаль районы, Лениногорск муниципаль районы, Мамадыш муниципаль районы, Менделеевск муниципаль районы, Минзәлә муниципаль районы, Мөслим муниципаль районы, Түбән Кама муниципаль районы, Яңа Чишмә муниципаль районы, Нурлат муниципаль районы, Питрәч муниципаль районы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Саба муниципаль районы, Сарман муниципаль районы, Спас муниципаль районы, Тәтеш муниципаль районы, Тукай муниципаль районы, Теләче муниципаль районы, Чирмешән муниципаль районы, Чистай муниципаль районы, Ютазы муниципаль районы.

3 статья. **Җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләре бирелә торган чор**

Җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләре биш елга бирелә.

4 статья. **Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен финанс белән тәэмин итү**

1. Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар бюджетларына бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гамәлгә ашырыла.

2. Җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар бюджетларына бирелә торган субвенцияләр күләмен исәпләп чыгару Җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар бюджетларына бирелә торган субвенцияләрнең күләмен исәпләп чыгару методикасы нигезендә әлеге Законга кушымта буенча башкарыла.

3. Җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар бюджетларына бирелә торган субвенцияләр күләме чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.

5 статья. **Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирле үзидарә органнарына түләүсез файдалануга тапшырыла торган матди чаралар**

1. Татарстан Республикасы милкендәге матди чаралар, җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү кирәк булганда, Тапшырыла торган матди чаралар исемлеге нигезендә җирле үзидарә органнарына түләүсез файдалануга тапшырыла.

2. Тапшырыла торган матди чаралар исемлеген әзерләү, раслау һәм матди чараларны тапшыру турында карар кабул итү Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең җир мөнәсәбәтләре өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан җирле үзидарә органнары тәкъдимнәрен исәпкә алып башкарыла.

6 статья. **Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда җирле үзидарә органнарының хокуклары һәм бурычлары**

1. Җирле үзидарә органнары дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда түбәндәгеләргә хокуклы:

1) муниципаль берәмлекнең уставында каралган очракларда һәм тәртиптә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен өстәмә рәвештә үз матди һәм финанс чараларыннан файдаланырга;

2) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле эшчәнлекне камилләштерү буенча тәкъдимнәр кертергә;

3) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарында дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча мәгълүмати, консультатив, оештыру һәм методик ярдәм алырга.

2. Җирле үзидарә органнары дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

1) Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырырга;

2) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органнарына дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләр буенча документлар һәм кирәкле мәгълүмат бирергә;

3) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең җир мөнәсәбәтләре өлкәсендәге вәкаләтле органына квартал саен дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында хисаплар тапшырырга;

4) җирле үзидарә органнарының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруларын тикшереп торуны башкаруда Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органнарына кирәкле ярдәм күрсәтергә.

7 статья. **Җирле үзидарә органнары дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының хокуклары һәм бурычлары**

1. Җирле үзидарә органнары дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары түбәндәгеләргә хокуклы:

1) җирле үзидарә органнарыннан һәм (яисә) җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затларыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләр буенча документлар һәм мәгълүмат соратып алырга;

2) җирле үзидарә органнарының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча эшчәнлеген тикшерергә;

3) җирле үзидарә органнары һәм (яисә) җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча ачыкланган закон бозуларны бетерү буенча язма күрсәтмәләр бирергә.

2. Җирле үзидарә органнары дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

1) җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле матди чараларны һәм финанс чараларын тапшырырга;

2) җирле үзидарә органнарының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруларын, шулай ук шушы максатларга бирелгән матди һәм финанс чараларыннан файдалануны тикшереп торуны башкарырга;

3) җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча мәгълүмати, консультатив, оештыру һәм методик ярдәм күрсәтергә.

## 8 статья. **Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында җирле үзидарә органнарының хисап бирү тәртибе**

Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында хисаплар җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең җир мөнәсәбәтләре өлкәсендәге вәкаләтле органына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән рәвештә хисап кварталыннан соң килә торган айның 10 числосына кадәр тапшырыла.

## 9 статья. **Җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тикшереп тору**

Җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тикшереп тору түбәндәгечә башкарыла:

1) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең җир мөнәсәбәтләре өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан – дәүләт вәкаләтләрен тиешенчә гамәлгә ашыру өлешендә түбәндәге юллар белән:

а) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында кирәкле документлар, хисаплар һәм мәгълүмат соратып алу;

б) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә шушы орган тарафыннан ел саен раслана торган план нигезендә күчмә тикшерүләр, шулай ук, кирәк булганда, планнан тыш күчмә тикшерүләр үткәрү;

2) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең финанс сәясәте өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан – дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен тапшырылган финанс чараларыннан максатчан файдалану өлешендә түбәндәге юллар белән:

а) дәүләт вәкаләтләрен башкару турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратып алу;

б) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә, кирәк булганда, күчмә тикшерүләр үткәрү, шул исәптән элек соратып алынган документларны, хисапларны, мәгълүматны карау нәтиҗәләре буенча, шулай ук закон бозуның ачыкланган фактларына бәйле рәвештә дә;

в) законнар бозуларны бетерү һәм аларны кисәтү буенча тиешле чаралар күрү;

3) җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы милкендәге матди чараларны түләүсез файдалануга тапшырган очракта, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең җир мөнәсәбәтләре өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан – җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен тапшырылган дәүләт милкәтен саклау һәм аннан тиешенчә файдалану өлешендә түбәндәге юллар белән:

а) дәүләт вәкаләтләрен башкару турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратып алу;

б) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә, кирәк булганда, тикшерүләр үткәрү, шул исәптән элек соратып алынган документларны, хисапларны һәм мәгълүматны карау нәтиҗәләре буенча, шулай ук закон бозуның ачыкланган фактларына бәйле рәвештә дә;

в) законнар бозуларны бетерү һәм аларны кисәтү буенча тиешле чаралар күрү.

10 статья. **Җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны туктату шартлары һәм тәртибе**

1. Җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны туктату түбәндәге очракларда Татарстан Республикасы законы белән башкарыла:

1) җирле үзидарә органнары дәүләт вәкаләтләрен җайга салу өлкәсендәге законнар таләпләрен үтәмәгәндә яисә тиешенчә үтәмәгәндә;

2) җирле үзидарә органнары һәм (яисә) җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары әлеге Закон таләпләрен бозуларны бетерү турындагы күрсәтмәләрне үтәмәгәндә;

3) Россия Федерациясе законнары яисә Татарстан Республикасы законнары җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен үтәү мөмкинлеген юкка чыгарырлык итеп үзгәртелгәндә.

2. Җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны туктату дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен тапшырылган Татарстан Республикасы милкендәге файдаланылмаган матди чараларны һәм финанс чараларын кире кайтаруны таләп итә.

3. Җирле үзидарә органнары дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча законнар таләпләрен үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең җир мөнәсәбәтләре өлкәсендәге вәкаләтле органы күрсәтелгән хокук бозулар ачыкланган көннән алып 10 көн эчендә җирле үзидарә органнарына аларны бетерү турында күрсәтмә җибәрә.

4. Ачыкланган хокук бозуларны бетерү турындагы күрсәтмә җирле үзидарә органнарына кергән көннән алып ун көннән дә соңга калмыйча һичшиксез каралырга тиеш. Күрсәтмәне карау нәтиҗәләре хакында Татарстан Республикасы

башкарма хакимиятенең җир мөнәсәбәтләре өлкәсендәге вәкаләтле органына кичекмәстән язма рәвештә хәбәр ителә.

5. Әлеге статьяның 1 өлешендә каралган очракларда, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең җир мөнәсәбәтләре өлкәсендәге вәкаләтле органы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каравына җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны туктату турында тәкъдим һәм тиешле Татарстан Республикасы законы проектын кертә.

11 статья. **Йомгаклау нигезләмәләре**

1. Әлеге Закон 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары әлеге Закон үз көченә кергән көннән алып өч ай эчендә аңа туры китерелергә тиеш.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ (Аппарат Президента Республики Татарстан / Татарстан Республикасы Президенты Аппараты)

Казан, Кремль
2015 елның 26 декабре
№ 109-ТРЗ

«Татарстан Республикасы муниципаль
районнарының җирле үзидарә органнарына
дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре
белән эш итү буенча Татарстан Республикасы
дәүләт вәкаләтләрен бирү турында»
Татарстан Республикасы Законына
кушымта

Җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар бюджетларына бирелә торган субвенцияләрнең күләмен исәпләп чыгару
МЕТОДИКАСЫ

1. Әлеге Методика җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнарның бюджетларына бирелә торган субвенцияләрне исәпләп чыгару өчен билгеләнә.

2. Җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан j муниципаль районына бирелә торган субвенцияләр күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$C_j^z = N^z \times H_j,$$

монда:

$C_j^z$ – Татарстан Республикасы бюджетыннан j муниципаль районына җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен бирелә торган субвенцияләр күләме;

$N^z$ – җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен j муниципаль районына дәүләт милке чикләнмәгән бер гектар җир кишәрлегенә субвенцияләр күләмен билгеләү өчен норматив (бер гектарга сум);

$H_j$ – j муниципаль районында дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре мәйданы (гектар).

3. Җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен j муниципаль районына бирелә торган субвенцияләр күләмен билгеләү өчен норматив түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$N^z = \frac{R}{\sum_{j=1}^{n} H_j},$$

монда:

R – җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга фаразланган чыгымнар;

n – муниципаль районнар саны.

4. Җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга фаразланган чыгымнар түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$R = (\sum_{j=1}^{n} S_j \times t_{усл.}) \times Z_1,$$

монда:

$S_j$ – j муниципаль районында дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен бирү буенча бер елда күрсәтелә торган хезмәтләр саны;

$t_{усл.}$ – дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен бирү буенча хезмәт күрсәтү өчен j муниципаль районы башкарма комитетының баш белгеченә кирәкле вакыт (ике эш көне күләмендә билгеләнә);

$Z_1$ – j муниципаль районы башкарма комитеты баш белгеченә, хезмәт өчен түләү фондына күчерелгән акчаны да кертеп, бер эш көне өчен түләнгән эш хакы.

5. j муниципаль районында дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен бирү буенча бер елда күрсәтелә торган хезмәтләр саны түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$S_j = К_{ср} \times Н_j,$$

монда:

$К_{ср}$ – дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен бирү буенча хезмәт күрсәтүгә бер гектарга туры килә торган мөрәҗәгатьләрнең уртача санын билгели торган коэффициент, ул 0,005 кә тигез.